*Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!*

ISSN 0136-7110

# Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ АВГУСТ * 2022 * КАЗАН

8



Вячеслав ШИЛОВ

Равил МОСТАФИН

## Көн дә шул...

Нинди халдер көн дә шул ук:
Кичен ят та, иртән тор.
Көне буе бер эш тә юк,
Уйнап әйтмим, чынлаптыр.

Беркая да барасы юк,
Барырга да ярамый.
Чыксаң керер җир куркыныч,
Адымны чик аралый.

Онытып, битлегең кимәсәң
Инде дустым, син чирле.
Тиз генә бетерә алмыйсың
Уйлап "ясаган" чирне.

Җир дә кечерәеп бара,
Нефть һәм газын суырткач.
Халкы кимергә тиештер бит,
Менә шушы чир йоккач.

Җир шарына сыймаганга
Сигез миллиард халык.
Яңа тормыш башланачак,
Бер миллиардка калып.

Даруны да шул чагында
Уйлап табачаклар ди.
Тик эш узгач, бу турыда
Күпләр язачаклар ди.

Ә хәзергә кырылалар,
Кими дөнья кешесе.
Иртәгә дә чыга күрмә,
Килә чирнең көчлесе!

Яшәү дип атала микән
Хәзерге бу яшәеш?
Халык була алырбызмы,
Бетәрбезме шул килеш?

Депутатның бер сарыгы,
"Сарык", диде халыкны.
Үзе дә шул көтүдән бит:
Кем икәнен онытты.

Менә шулар бутый инде
Затлы халык кавемен.
Чыбыркысын ташлаган да,
Алыштырган киемен.

Хамелеоннар һәм еланнар
Төс үзгәртә, чагалар.
Ярлы халык акча җыя –
Үлә бала-чагалар.

Александр АЛЁШИН






## ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Смартфоннар һәм айфоннар заманыбызның төп әйберләренә әверелде бугай. Алардан башка тормышыбызны күз алдына китереп булмый. Транспортта, урамда, чиратта, ә кайчагында хәтта руль артында утырганда да кешеләр гаджетларыннан аерылмыйлар. Еш кына күрергә туры килә – кафеда яшь егетләр-кызлар, аралашып утырасы урынга, күзләрен кечкенә экранга төбәгәннәр. Әгәр бер-берсенә караган йә сөйләшә икән – боларның бары тик гашыйклар гына булуы мөмкин...

**Л. ИБРАҺИМОВА**

КАЗАН

Укучыбызның күзәтү нәтиҗәләре Шомбай агабызда зур кызыксыну уятты:

**– Элек кенә ул бәхетлеләр сәгать күзәтмәгәннәр, хәзер алар смартфон күзәтмиләр...**

**Шәүкәт ГАЛИЕВ**

## ГЫЙБРӘТ

«Аягым юк» дип гел кимсенмә,
Әрнүләрең сызма тирәнгә,
Ташла зарлануны,
Башсызлар да
Йөриләр бит әле тирәндә!

## БАКЧАДА ЙӨРИ БЕР БАБАЙ

Бакчада йөри бер бабай
Ияртеп чибәр кызын.
Барып сүз кушар хал юк,
Калдырмый бит ялгызын!

Утка килгән күбәләктәй
Әйләнәм кыз катында,
Карт шунда таяк күтәрә:
– Тимә минем катынга!



Николай ВОРОНЦОВ



Ринат АБЗАЛОВ

# Файдалану материалы

"Хезмәт төбе – хәзинә", – дип өйрәттеләр безне балачактан. Әмма хәзерге вакытта эш эзләгәндә хезмәтен дә, хәзинәсен дә бик җентекләп, төпләп сайларга кирәк. Беренче карашка, шартлары менә диган: ирекле график, көненә ике-өч эш сәгате, акчасын күрәп аласың. Дөрес, карьера мөмкинлекләре бик чикле, ләкин акча күктән явып торганда бу турыда уйлап торасыңмыни? Һәм эш табарга теләүчеләр кетүләре белән наркобизнеска китәләр – махсус урында яшерелгән наркотиклар белән эш итүче, ягъни закладчик урыннары җитәрлек: өлгерлегең генә булсын.

Казандагы күпкатлы йортларның стеналары җиңел акча вәгъдә иткән белдерүләр белән тулы, Интернетта да шул ук хәл. Хезмәт хакы – көненә 15 меңнән. Хезмәт вазыйфалары бик гади. Башта залог буларак берничә мең калдырасың, йә паспорт белән фоторәсемеңне җибәрәсең. Аннан соң эш бирүче "клад"ның – пакетка салынган наркотикның координаталарын җибәрә. Чираттагы эш – "клад"ны вак пакетларга бүлгәләп, район буенча яшереп чыгарга һәм клиент аны таба алсын өчен, ул урыннарның адресларын телефоннан хәбәр итәргә кирәк. Уйлап карасаң, җиңел эш. Ә менә аның өчен статья бик хәтәр –эләксәң, 20 елга кадәр төрмә срогы көтә.

Гадәттә бу хәвефле эшкә яшьләр ялланa. Мәсәлән, Казанда бу елның язында унбишәр граммлы ике төргәк мефедрон белән 15 һәм 19 яшьлек ике кызны тоткарлаганнар. Ә Чистайда өч яшүсмерне тотканнар, алар шунда ук наркотик яшерелгән алты урынны күрсәткәннәр. Полицейскийлар аларның бу көнгә нигә төшкәннәре белән кызыксынгач, егетләр фильмнарда күрсәтелгән романтика, күп акча һәм чын ирләрчә яшәүгә омтылу белән аңлатканнар. Хәзер алар ирләр тормышының нечкәлекләрен чәнечкеле чыбык артында өйрәнәчәкләр.

Бу хәвефле бизнеска яшь романтиклар гына түгел, ә гаиләләре белән баручылар да бар икән. Күптән түгел Казанда ир белән хатынны 7 һәм 8 елга каты режимлы колониягә озатканнар. Гаилә бизнесы киң колач белән, җитди итеп куелган булган – аларның өендә бер килограмм чамасы наркотик матдәләр һәм пакетларга бүлү җайланмасы табылган. Ә Зеленоградта яшәүче бер ханым үзе үк наркобизнеска алып килгән 13 яшьлек улын полициягә тапшырган. Шулай итеп ул үзенең хәлен җиңеләйтергә өметләнгәндер, әмма балиг булмаганнарны җинаять эшчәнлегенә тарту өчен бер статья алган.

Һәм мондый мисаллар җитәрлек. Криминаль эшмәкәрлек шундый киң колач алган ки, күптән түгел Царицыно бистәсендә яшәүчеләр оборона тотарга мәҗбүр булганнар: аларның йортлары тирәсендә закладчиклар артык еш күренә башлаган. Шикле бәндәләр урамнар буйлап каңгырып йөргәннәр, трансформатор будкаларында, клумбаларда казынганнар. Бистә кешеләренә хәтта кизү торырга туры килгән. Аларның уяулыгы яхшы нәтиҗә биргән: берничә закладчик клиентлары белән бергә полициягә тапшырылган. Халыкта хәтта: "Йоклап китә алмасаң сарык түгел, закладчиклар сана" диган шаяртулы әйтем дә барлыкка килгән.

Оперативниклар белә – наркотик таратучыларның эзенә төшү әллә ни кыен түгел. Аларның 95 проценты гадәттә беренче "операция" вакытында ук эләгә. Һәм җинаять кодексының наркотиклар сату, саклау һәм сатып алу турындагы 228 нче статьясын юкка гына "халык статьясы" дип йөртмиләр бит. Төрмәләрнең яртысы наркотикларга бәйле җинаятьчеләр белән тулган. Ләкин болары "вак балык". Балыкның эрерәген тоту күпкә катлаулырак. Алар кулында – катлаулы махсус җайланмалар, яшерен функцияле мессенджерлар һәм Даркнет дип атала торган интернетның яшерен өлеше. Өстәвенә, акча, кыйммәтле адвокатлар, коррупцион элементлар...

Наркоакулалар рәхәтләнеп иректә йөзә бирә, ә вак балыкның язмышы – төрмә срогы һәм җимерелгән тормыш. Алар бит үзләренең закладкалары кебек, бары бер тапкыр файдалану материалы гына...


**Людмила САФИУЛЛИНА**




Вячеслав ШИЛОВ



Игорь КИЙКО



Виктор ФЁДОРОВ

## ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Сүз тотмауда гаепләмәсеннәр дисәң, сүз бирмә.

Ялагайлана белгән яла да яга белә.

Белем алганда мисаллар, кагыйдәләргә караганда, файдалырак.

Элек актрисалар йолдыз булырга телиләр иде, хәзер йолдызлар актриса булырга маташа.

Аборт ясату яклылар – инде туарга өлгергәннәр.

Ялгыз булмаганда ирекле булу җиңелрәк.

Диагнозлар кую шундый уңышларга ирешә ки, сәламәт кешеләр бөтенләй калмады диярлек.

Үлем ул – тынгылык, ләкин үлем турындагы уйлар безгә тынгы бирми.

**(Фикер ияләре мәҗлесендә язып алынды)**

Валерий ТАРАСЕНКО







• • •

Гендиректор баш бухгалтерын пыр туздыра:

– Сезнең компьютер фирмадагы иң каттәсе, ә сез счет төймәләре белән эш итәсез! Клиентлар алдында оят!

– Иманым камил, бу счёт компьютерга караганда күпкә ышанычлырак. Бер генә секундка күз алдыгызга китерегез – офиска салым инспекциясе килеп керә: "Стенага терәлеп басыгыз, кулларыгызны – баш артына!" – диган команда бирелә. Шундый чакта компьютердагы документларны ничек юкка чыгарасыз? Ә мин кулларымны счёт белән күтәрәм, бөтен төймәләр бер якка авыша – шәпме! Берәү дә бернәрсәгә бәйләнә алмый!

• • •

ГАИ инспекторы – йөртүчегә:

– Бумажнигыгызны ачыгыз!

– Бәлки, багажникнымыдыр?

– Әйе, әйе, шулай, һәрвакыт гамәлләрне ашыктырам!

• • •

– Доктор, мин авырып киттем! Нишләргә?

– Тизрәк терелегез!

– Рәхмәт, доктор!

• • •

Бер кыз белән балалар бакчасына да бергә йөрдек, мәктәптә бер класста укыдык, көллияттә дә бер төркемдә идек... Одноклассниклардан карыйм: аңа – 27, ә миңа – 38...

• • •

– Безнең улыбыз тагын минем бумажниктан акча алган, – дип, ачу белән әйтеп куйды атасы.

– Нигә ул дип уйлыйсың? – диган шиген белдерде хатыны баласын яклап, – бәлки, мин алганмындыр?

– Алай булырга мөмкин түгел, чөнки анда әле бераз калган иде.

• • •

Әтисе – улына:

– Мәктәптән соң, улым, институтта укырсың, югары белем алырсың.

– Ә нәрсә ул югары белем?

– Ул – шул, – дип җавап бирә әтисе, – элек аны урта белем дип әйтәләр иде...




## КЫЗЫЛ КАР ЯУГАЧ

Хакимият органнарының үз мөрәҗәгатьләренә биргән җаваплары белән татарстанлыларның 40 проценты гына риза. Чиновникларга моның өчен бары тик 10 көн генә бирелгән булуга карамастан, алар җавап бирү белән бик ашыкмыйлар. Иң акрын эшләүче Дәүләт торак инспекциясе булып чыккан. 111 мөрәҗәгатьнең 35 енә ведомство бер айдан гына җавап биргән. Өстәвенә, күп очракта аларның эчтәлеге "мәсьәлә акча булгач хәл ителәчәк" кебек буш сүзләргә кайтып кала – гади итеп әйтсәк, кызыл кар яугач.

## ҮЗЛӘРЕНӘ КҮП АЛГАННАР

Чаллы башкарма комитеты шәһәрдәге бөтен мәет җирләү эшләрен "Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе" идарәсенә йөкләгән. Исполком җитәкчесе имзасы торган документ буенча, оешма үлгәннәрнең туганнарына документлар тутыру, табутлар белән тәэмин итү, җирләү, каберлекләрне карау кебек төрле хезмәт күрсәтергә тиеш. Татарстанның монополиягә каршы көрәш комитеты бу хәлне конкуренция турындагы законны бозу дип санаган һәм башкарма комитет чиновникларына карата җинаять эше кузгаткан.

## ДИПЛОМ БӘЯСЕ

Тикшерүчеләр югары уку йортларындагы чираттагы ришвәтчелек очрагы өстендә эшлиләр. Бу юлы аларның кармагына КНИТУ-КХТИ эләккән. Ришвәт алуда Югары икътисад мәктәбендә эшләүче укытучы ханымны гаеплиләр. Тикшерүчеләр фикеренчә, бернигә ел дәвамында бу доцент дәресләрдә күренмәүче студентларга билгеләнгән түләү өчен экзаменнар һәм зачётлар куеп килгән. Өстәвенә, ханым алар өчен диплом эшләре язарга да уңайсызланып тормаган. Имтиханда яхшы билге – 10 мең, ә әзер диплом эше 30 мең сумга бәяләнгән.


## КАЗАНЫМ, КАЗАНЫМ...

Numbeo порталының халыкара аналитиклары фикеренчә, Россия шәһәрләре арасында яшәү бәясе буенча Казан өченче урынга чыккан. Мәркәзебез беренчелекне Мәскәү белән Санкт-Петербургка биргән. Белгечләр исәбе буенча, казанлыга туган каласында яхшы яшәү өчен 40 мең сум кирәк икән.




Игорь КИЙКО






Валентин ДУБИНИН




• • •

Укучы мәктәптән өенә кайта һәм ати-әнисенә хәбәр итә:

– Белмим, минем укытучыга нәрсә белән ошагансыздыр, ләкин ул сезне тагын күрергә тели...

• • •

Кичә дәрес әзерләдек. Әти миңа кычкырды, кечкенә энем акырып елады, әни инша язды!

**Валентин ДУБИНИН**




## МӘКТӘП ИНШАЛАРЫННАН ҖӨМЛӘЛӘР

• Романның дәвамын укыганда без инде яратырга өлгергән, шулай ук яңа, таныш булмаган хәрефләр белән дә очрашабыз.

• Италия картада резин итекне хәтерләтә, чөнки ул өч яктан су белән әйләндереп алынган.

• Обломовның буш вакыты булганда, ул диванда яткан һәм фәлсәфи уйларга бирелгән, ә вакыты булмаганда диванда болай гына яткан.


• Колумб башка кая йөзгәнен, ә аннан соң каян йөзгәнен белмәгән.

• Әдәбиятта канатлы сүзләр куллану мисалы: Гоголь хикәясендә Иван Никифорович Иван Ивановичны «ата каз» дип атаган.

**Иншаларны Константин ЧАХИРОВ тикшерде.**

• • •

Укытучы иншаларны елый-елый тикшерде: хәзер ул җәйне ничек уздырырга икәнен белә иде, ләкин еллар ул түгел шул...




**Николай ВОРОНЦОВ**

Михаил МИХАЙЛОВ

# Кызыклы тәкъдим

Ёжиков бәрәңге пешерде, тозлы балык кисеп куеп кичке ашын ашады, этен туйдырды һәм компьютер каршына барып утырды. Почтага килгән хатларның берсе аның игътибарын җәлеп итте. Нindидер бер компания, исем-отчествосы белән мөрәҗәгать итеп, аны кандидат буларак сөйләшү өчен кызыклы тәкъдим белән офисына чакыра иде.

– Берәр хәйләдер инде! – диде үзалдына Ёжиков, ләкин кызыклы тәкъдим турындагы хат һаман аның башында бөтерелде.

– Кем белә бит? – дип уйлап куйды ул. Дәрес, мәктәптә ул уртача укыды, күктән йолдызлар тотмады, институтның да иң кечкенә конкурс булганына кереп, аны тартып-йолкып кына бетереп чыкты, һәм гомере буе бер үк урында эшләде...

Офис ишегеннән атлап керү белән аңа ярып салдылар:

– Компания хуҗасы җитәкләгән комиссия меңләгән лаеклы кандидатлар арасыннан сезне сайлап алды! Сезгә генераль директор урыны тәкъдим итәбез.

– Гафу итегез, – дип мыгырдады Ёжиков, – ә мин нәрсә белән шөгыльләнергә тиеш булам соң?

– Берни дә эшләргә кирәк булмаячак! Безнең хуҗа көтелмәгән тәҗрибәләр ясарга ярата, шуңа күрә директор урынына иң булдыксыз кешене куярга булды. Моның мәгънәсе бик гади: әгәр өстәгеләр комачауламый икән, астагылар барысын да тиешенчә башкара!

– Ә булдыра алмасам? – диде югалып калган Ёжиков.

– Артык сүз кирәкми. Барысы да инде хәл ителгән! Бүген сезнең кандидатурагыз раслау үтәчәк, ә иртәгә көн ахырына чакыру хаты көтегез...

Ёжиков өенә канатланып кайтып керде: менә ниләр була бит дөньяда!

Иртүк эшенә шалтыратып, отпуск исәбенә бер көн алды һәм компьютер каршына утырып, киеренке караш белән хәбәр көтә башлады. Эш көне беткәндә хат килеп төште. Анда борчу өчен чын күңелдән гафу үтенү һәм генераль директор билгеләүнең гаять четерекле һәм җаваплы эш икәнлеге турында сүз бара иде. Комиссия кандидатларны тагын бер кат тикшереп чыкканнан соң, аннан да булдыксызрагы табылган, һәм шуны билгеләгәннәр икән. Хат уңышлар теләү белән тәмамлана иде, һәм бу Ёжиковка гадәти хәленә кайтырга ярдәм итте. Кичке ашка ул макарон белән ике сосиска пешерде, һәм этенең тугры күзләренә карап алгач, сосисканың берсен аңа бирергә булды...

Василий АЛЕКСАНДРОВ









# Удмурт ядкаре

*Лопшо Педунь (Шаян Фёдор) – удмурт фольклоры каһарманы. Ул – байларның комсызлыгын күрсәтеп, күңелле итеп ахмаклыктан көлеп, үткен сүз белән бозыклыкны мәсхәрәләп яшәүче зирәк һәм оста сүзле ир заты. Аңа багышланган гыйбарәләр, акиятләр чын мәгънәсендә удмурт халкының рухи хәзинәсе булып санала.*

*Соңгы вакытларга кадәр Лопшо Педунь, татардагы Хуҗа Насретдин кебек, халык иҗаты җимеше булып санала иде. Әмма Удмуртия Республикасы Игринский районының тарих өйрәнүчеләре XIX гасыр ахырында Лопшо Педунь чынлап та бу якларда яшәгән дип саныйлар. Бу турыда бәхәсләшергә була, әлбәттә, ләкин Шаян Фёдорга багышланган туристик маршрут уңышлы эшләп килә инде.*

## НЫКЛЫ ТЕГЕРМӘН

Берзаман бай Ганя Шаян Фёдорны очраткан.

– Синең шаяртырга оста икәнеңне беләм. Әйдә, мине алдап кара әле, – дигән бай.

– Алдавын алдар идем дә, хәзер вакытым юк: Комакта тегермән буасы киткән, шунда ашыгам – бушлай балык җыеп калырга кирәк.

Ганя шунда ук өенә кайтып ат җиккән дә Комакка элдерткән. Тегермән янына килеп туктаса – күрә: тегермән берни булмагандай, элеккечә эшләп тора. Ганя тегермәнчедән сорый:

– Син кайчан буа буарга өлгердең соң әле?

– Менә сиңа мә! Ул инде ун ел эшләп тора.

Шунда Ганя Шаян Фёдорның үзен алдаганын аңлап алган.

## АКЧАБАЙ КАЙСЫ ЯКТА?

Берзаман Шаян Фёдор Алабуга ярминкәсенә башкалардан иртәрәк килгән. Сәүдә рәтләрендә иң шәп урынны алган, йөз адым үлчәгән дә шул урында алга-артка йөри башлаган.

Менә зур олау белән сәүдәгәр килеп туктаган һәм Шаян Фёдордан сорый икән:

– Карале, дус кеше, син нишләп минем урынны алып монда таптанасың соң әле?

– Бүген бу урын минеке булачак! – дип җавап бирә аңа Шаян Фёдор. – Мин сәүдәгәр, минем олау синекеннән зуррак, хәзер ул килеп җитә, бу урынны мин беркемгә дә бирмим.

– Үзең кайсы яклардан буласың соң? Сине беркайчан да күргәнем юк.

– Акчабайдан мин, ишеткәнең бармы?

Сәүдәгәрнең мондый як турында ишеткәне булмаган, ләкин сер бирмәгән. Ул арада ярминкәдә халык арткannнан-арта барган, сәүдә шәп киткән.

– Их! – дигән Шаян Фёдор, башын кашып. – Нигәдер минем товар тоткарлана бит әле. Акчабайдан юл авыр, төштән соң гына килеп җитәр, мөгаен.

– Соң сат миңа бу урынны, – дип үгетли башлаган сәүдәгәр. – Йөз сум бирәм, һәр адым өчен – бер сум! Килештекме?

Бераз киреләнгән булып кыланганнан соң, Шаян Фёдор ризалашкан һәм акчаны алган. Теге сәүдәгәр сорый икән:

– Шулай да әйт әле, ул Акчабай кайсы якта соң?

– Башта синең якта иде, ә хәзер – минем якта.

– Ничек инде? – дип гаҗәпләнгән сәүдәгәр.

– Синең йөз сумың бар идеме? Аны ялган белән кесәңә салып баедыңмы? Ә хәзер аны мин үз кесәмә салдым.

Шунда сәүдәгәр, үзе кеше алдарга оста булса да, үзенең алданганын аңлаган.

## КӨННЕ НИЧЕК КЫСКАРТЫРГА

Бер авыл баена җәйге көн кыска тоелган: батраклар-хезмәтчеләр кырга чыгарга да өлгермиләр, кире кайтырга вакыт җитә. Болай бит аларның эшлисе эшне башкарырга өлгермәүләре дә мөмкин. Ул Шаян Фёдорга киңәшкә килгән.

– Син көнне ничек озайтырга икәнен белмисеңме?

– Беләм! – дигән Шаян Фёдор, бу комсызны ничек акылга утыртуы турында уйлап. – Биш пот он бирсәң – ярдәм итәм.

– Уны да жәл түгел, тизрәк өйрәт кенә, – дигән бай.

– Өстеңә калын күлмәк ки, бишмәт, барысы өстеннән толып, аягыңа – киез итек, ә башыңа – сарык тиресеннән бүрек. Кулыңа сәнәк ал, биек каенның очына мен һәм урыныннан китмәсен өчен кояшны сәнәгең белән тотып тор. Аңладыңмы?

– Барысын да аңладым. Рәхмәт киңәшең өчен.

Икенче көнне бай барысын да Шаян Фёдор кушканча эшләгән. Ул елны җәй бик эссе булган. Бай каен очында утыра икән – бер ботак та куләгә бирми, хезмәтчеләрнең эшләгәнен күзәтеп, сәнәк белән кояшны тоткарлап утыра. Кызулан сыртыннан елга булып тир ага, куллары талган, чак-чак җиргә егылмый гына. Һәм көн аңа бик тә озын булып тоелган. Төш вакытына мунча ләүкәсендә чабынгандай булган бай, гүя аны сукага җигеп, чыбыркылап җир сөргәннәр. Төшкән бу каеннан.

– Ярый, егетләр, бүген бик шәп эшләдегез, бүгенгә җитәр, – дигән.

Ә батраклар шат: арырга да өлгермичә, бары тик ярты көн эшләгәннәр бит. Күтәренке күңел белән өйләренә таралышканнар болар.

Шулай итеп, комсыз бай көнне озайткан. Моның өчен ул Шаян Фёдорга ун пот он биргән, өстәвенә, шәпләп сыйлаган да.




Николай ВОРОНЦОВ




# ЧЫНБАРЛЫК КӘРТИНКӘ ТҮГЕЛ ШУЛ...

Кадерле Чаян! Мәгълүм вакыйгалар сәбәпле, күп кенә һава аша аралашу юллары ябылуы Сочи шәһәрен монополист ясады. Ә инде җирле кунакханәләрнең хуҗалары туристлык бизнесының корольләре булды. Көндәшләр юк, кунакларны ничек кирәк шулай сыга аласың хак бәядән. Минә безнең гаилә дә мондагы кунакчыллыкның рәхәтен күрде.

Шунысын әйтеп үтик: башта ук Казанның "Бәхетле ял" турагентлыгында безне кочагына алачак бәхетле ялыбыз белән тәбрикләделәр. Офыклары, шәфәкъләры күренеп торачак диңгез күренешләре, күп йолдызлы әллә ни кыйбат та булмаган кунакханәләрен мактадылар. Хәтта кәртинкәләрен күрсәтеп, һушны алдылар...

Хакыйкать чынбарлыктан ерак булып чыкты. Көтмәгәндә безне кечкенә балалар белән бәләкәй генә кунак йорты "Даниэль"дә урнаштырдылар. Вәгъдә ителгән уңайлыкларына – шыксызлык (иске-москы җиһаз, сытылган панцирьлы караватлар, тишек-тошык урын-җир җәймәләре һ. б.), тыныч һәм уңайлылык урынына – тимер юл депосы, поезд гудоклары һәм тәгәрмәч тыкылдавы... Диңгез күренешләре урынына – каргалы чүп-чар тавы...

Паралич суккандай булды. Бераздан диңгезгә хәтле ярты сәгать чамасы җәяү барасы икәнлеге ачыкланды. Анысы да җайлы сукмактан түгел, машина юлыннан икән. Таптап китмәсеннәр дип, гел артка карап барышлы. "Даниэль"нең үз пляжы юк – теләсә кая барып коена аласыз, диделәр. Шулай да ишегалдында 2x2 зурлыгында ни төсле дип әйтергә белмәгән, бассейн шикелле су тутырган күллавек ясаганнар, ул да булса болганчык.

Балалар өчен кызыктырырлык бер чара да юк, ул турыда уйлап караучы да күренмәде. Администрациянең төп бурычы – туристларны ничек булса да тизрәк номерлардан чыгару, яңгыр явамы, җил-давылмы, бар борчулары – андагы хезмәткәрләргә тел тидермәү.

Күбрәк хезмәткәрләре турында кайгырталар. Бәлки алар арасында ягымлылары да, мәрхәмәтлеләре дә булгандыр, ләкин андыйлары очрамады, бердәнбер кухняда эшләүче Фатыйманы искә алып китсәк кенә. Тупас һәм акырып йөрүче, гел "Ярамый!" дип кабатлаучы тәртипсез администратор Галинаны арт ягына тибеп куарга иде. Ярамый, чөнки ул "Даниэль" хуҗаларының туганы икән.

"Даниэль" кухнясын җырга салырга була – тәмсез, ямьсез, бертөрле, ашларына төкереп, якындагы берәр кафега барып рәхәтләнеп ашыйсы, эчәсе, күңелле ял итәсе килә. Ә бит Галина чын күңеленнән – бу ризыклар да әле безнең өчен әрәм икән дип уйлый иде. "Бөтен уңайлыклар тудырып, тереклэр бозып бетергән сезне, мисырлылар уңай шартлар тудырып, үсендергән... Шуңа кылтаясыз – тегесе болай түгел, монысы... Нәрсә бирәләр, шуны ашагыз!" Кайберәүләр бу хәлләргә чыдый алмыйча, вакытыннан алда кайтып киттеләр.

Менә шундый онытылмаслык тәэсирләр... Мондый ял итү түләнгән бәя белән чагыштырырлык түгел. Үзебез дә гаепле, турагентларның тәмле телләренә, күрсәткән матур кәртинкәләренә ышанып барабыз бит...

Р. М-на.






Василий АЛЕКСАНДРОВ




Рөстәм ЗАРИПОВ

## ВАЗГЫЯТЬ!!!

Былбылларга белдерелгән отставка,
Миллион баш чучка чиный туган якта,
Күпләп житештерә торгач химикатлар,
Өч хәрефле чир узына, кая бакма...

Әтрәк-әләм, һава бозып, акча эшли,
Әтрәк-әләм телне, моңны, рухны көчли;
Бар затлыга, талантлыга алар үчле,
Көлешәләр, вакыт-вакыт, кешни-кешни...

• • •

Яшиләр гел бергә, күзгә-күз, йөзгә-йөз,
Алар гүя игез, үлчәмнәре тигез..
Тайпылыш юк уңга, тайпылыш юк сулга,
Еллар узә, алар шул халәткә түзә...

Ничек шулай мөмкин? Мин табышмак чишәм,
Үрнәкме аларга идән белән түшәм?..
Шулай була микән бер-береңне сөйсәң?
Ни әйтерсез, әгәр пар килгәннәр дисәм?

• • •

Бездә һәр тармакны чуртан сөйри,
Тырыша аккошы, кысласы...
Омтылабыз якты киләчәккә...
Алга китеп булмый, кыскасы...

# Абау!

## ХАТЫН-КЫЗНЫ ЭЗЛӘГЕЗ

9 кызга – 10 егет дигән элеккеге статистика үз актуальлеген югалткан. Тикшеренүләр нәтиҗәсендә, илдә репродуктив яшьтәге хатын-кызлар җитешми. Соңгы ун еллыкта 20 дән 29 яшькә кадәрге хатын-кызлар саны 4,5 миллионга кимегән. Белгечләр, хатын-кызлар җенесенә кытлык туучылар санының тагын да кимүенә китерер, дип куркалар, чөнки ул 2014 елдан бирле кими инде.

## ЙӨКЧЕ, ЭШЧӘН ЕГЕТ

Шереметьево аэропортында чираттагы чемодан карагын кулга алганнар. Мәскәү–Бишкәк рейсы бортына чемоданнар ыргытып, йөк тәүче багаждан 21 миллион сум акча алырга җитешкән. Аның сүзләренә караганда, ул ике чемоданда зур сумма турында мәгълүматны таможня инспекторыннан алган. Хәзер икесе дә тикшерү астында. Полиция бу ялган акчаларны беренче генә тапкыр алулары түгел дип шикләнә, чөнки тыйнак йөкче хезмәт хакына үзенә яңа «Мицубиси Аутлендер» сатып алган.

## БЕР ШТРИХ БЕЛӘН

Биробиджанның полиция бүлекләренең берсендә бер штрих белән сорау алу беркетмәсенә төзәтмәләр кертkәннәр. Кыш көне җирле ханымга карата мошенниклыкта шикләнеп, җинаять эше кузгатканнар. Тик документлар прокурор өстәленә эләккәч, ул беркетмәдә җөмләнең төзәтелүен күреп алалар «Җинаять кылуда гаепне танымыйм»ны кемдер штрих белән бик пөхтә итеп «таныймга» төзәткән. Тикшерүче һәм бүлекнең өлкән лейтенанты беркетмәне төзәтүдә үз гаепләрен танымаганнар. Хокук сакчылары дәлилләрне фальсификацияләү турында тагын бер эш кузгатканнар.

## БАЛЫК ЮКТА
## БАЛ КОРТЫ ДА – ЧУРТАН

АКШның Калифорния штаты суды тулы бер биологик төрне үзгәрткән. 2019 елда ук балык һәм аучылык ресурслары буенча Комиссия бал кортларына сак статусы биргән. Җавап итеп, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре судка биргән, янәсе, бөҗәкләрнең балыкларга бернинди катнашы да юк. Ниһаять, эшкә тулысынча нокта куелган. Суд сак астында елга кыслалары, креветкалар һәм бер төр коры җир өсте әкәм-төкәмнәре бар икән, алар хәтта балык булмасалар да, бал кортлары кайсы яклары белән начаррак, дигән карарга килгән. Штат законнары буенча, юридик яктан хәзер бал кортлары да – балык.

Дамир МОРТАЗИН

# Бәхеткә чыдый алмау

Мәдинә күптән кияүгә чыгарга уйлап йөри иде, ләкин нигәдер һаман җае чыкмый торды. Башта институтны бетерәсе булды, аннан соң түләүле курсларга йөреп, үзенең тән-фигура, килеш-килбәт җитешсезлекләреннән арынды, шуңа өстәп социаль челтәр белән буталып йөрде. Ара-тирә – төнге клублар, шау-шулы очрашулар, кызыклы кешеләр арасында буталулар... Тормыш гөрләде, чәчәк атты, әйтерсең лә бар дөнья бәйрәм генә!

Ниһаять иреннәренә һәм күкрәгенә пластик операцияләр ясаткач, ул гаилә корырга ният кылды. Ире болай хәйран әйбәт кеше сыман – эчми, тартмый, муен артлары кырылган, шәрә аягында туфли, ягъни модный... Исеме дә шәп – Макс.

Шулайлы тормыш башладылар. Бер көн яшәделәр, ике көн, бер атна. Шул көннәрнең берсендә Макс Мәдинәдән аш пешерүен сорады.

– Аш ашыйсым килә! Туйдырды китерелгән фаст-фуд...

Мәдинә кабынып китте:

– Мин сиңа плитә янында аш пешереп торыр өчен кияүгә чыктыммы? Яшьлегемне, матурлыгымны әрәм итеп!..

Ишекне шапылдатып япты да сердәше Ләлә янына китте. Ул аны акылы өчен хөрмәт итә иде. Әле аның төркемендәге язылучылары да ун кешегә артык.

– Кара син аны! Нинди оятсызлык! – дип чыгырыннан чыкты Ләләсе. – Хатын муенына утырырга икән исәбе! Менә минем ирем өйдә бөтенесен үзе эшли иде. Нәрсә куштым, шуны үтәде...

– Син аерылган шулмы?

– Әйе... Бу ирләр бөтенләй бәйдән ычкындылар! – дип, сердәше ачуын ныграк кабартты. – Алар бит безнең көне буе эшләп арыганыбызны да аңламыйлар. Шопинг, фитнес, солярий... Бер эпиляция эшләтү генә ни тора!

– Шулай... – дип куәтләде аны Мәдинә.

– Ир булып әллә кем булган! Миңа хәзер гүргә кергәнче аңа аш пешерергәме? Башкалар әнә үзләренең джипларында Куршевелларда оча, ә бу үзенә ризык әзерләп ашый алмый!

– Әйтмә... – дип, Мәдинә пичәт сугып куйды аның сүзләренә.

– Ошамый икән, юлларына – ак җәймә! Башкалар бетмәгән!

– Ә менә бу сүзең белән мин килешмим, – диде кинәт Мәдинә. – Соңгы тренингта коуч нәрсә дип әйтте безнең "Ирләрнең йөрәген ничек яулап алу турында"гы кызыксынуыбызга...

– Ни турында дисең?.. – дип кабатлап сорады Ләлә.

– Статистика буенча – фәндә чутланган... Ирләр хатын-кызларга караганда күпкә азрак икән. Димәк, алар – сайлап алучылар. Күз алдыңа китер, араларыннан бер чибәркәе табылыр да аш та пешерер, кибеткә дә йөгерер, балалар да табар. Берсенең дә ялгыз калып, күке сыман күкелдәп утырасы килмәс. Шулай итеп минем Макс та тутүт...

Мәдинәнең сүзләренә Ләлә, кашларын җыерып, уйга калды...

Бер ай чамасы Мәдинә әниләрендә яшәп торды. Максның шалтыратуларына һәм телефонына хәбәр җибәрүләренә җавап бирмәде. Ләкин күңеленә корт керде: ул анда берүзе генә ничек яши икән, коры-сары ашап үлмәде микән? Берзаман ул аның белән гаилә корган өйләренә, болай, "кызыксынып" кына кереп чыгарга булды.

Үзенең ачкычы белән ишеген ачты – һәм тыныч кына эчкә атлады. Күңелне кытыклап, аш бүлмәсеннән тәмле ис бөркелде.

– Макс, җаным, менә синең яраткан токмачлы ашың пешеп тә җитте! – диган ягымлы хатын-кыз тавышы ишетелде. – Тизрәк кил, суына күрмәсен...

Мәдинә шул якка юнәлде. Аның каршысында кулына чүмеч тоткан сердәше Ләлә пәйда булды...





Илдар НӘФИЕВ



Максим СМАГИН




• • •

– Без – атлар, – ди бер ат ишәккә, – кешенең дуслары арасында иң игелекле кавем. Без кешеләрнең хезмәтләрен җиңеләйтәбез, тормышларын бизибез, яуда да без алыштыргысыз, ял сәгатьләрендә дә...

– Бәлки шулайдыр да, – дип җавап бирә аңа ишәк. – Әмма вакыт узу белән сезне машиналар кысып чыгарачак һәм сездән истәлек кенә калачак. Ә менә без, ишәкләр – мәңгелек...




• • •

Су кызы әтисе янына йөзеп килә.

– Әти, мин әле генә бер яхшылык эшләдем. Кешеләр ниндидер бер хайванны бау белән бәйләп су төбенә ыргыттылар, ә мин бауны кисеп ташладым. Яшәсен әле иректә!

– Әйбәт булган, кызым! Ләкин бүтән алай эшләмә.

– Ник?

– Чөнки ул хайван түгел, ә водолаз иде...






Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

# "Шахта" җыры

Моннан берничә еллар элек һинд биюе ансамбленең җитәкчесе булып йөргән чакларым. Сценарийлар язып, концертлар алып барам. Казанда бер бәйрәм дә бездән башка үтми.

Чыгышларыбыз күп булса да, берсе бигрәк тә истә калды...

Сабантуй бәйрәме. Без мәйданчыкта концерт куябыз. Төрле коллективлар катнаша. Әмма һәммәсе дә бию коллективлары: халык, бал биюләре. Ә без – һинд биюләре белән. Концертны ДК директоры алып барырга тиеш иде. Ләкин ул каядыр юкка чыкты. Теләсәң, теләмәсәң дә программаны миңа алып барырга туры килде.

Шулай, бәйрәм гөрли, биючеләр үз чираты белән чыгыш ясыйлар. Халык, шашып, кул чаба. Шул вакыт минем яныма өлкәнрәк ир кеше килеп басты:

– Сеңлем,"Шахта"җырын башкарсагыз иде, – ди.

Мин югалып калдым:

– Абый, – мин әйтәм, – бездә бит җырлар юк, биюләр генә.

– Шул бию арасына "Шахта" җырын да кушсагыз була бит инде...

– Юк, булмый, – дим. – Бездә аны җырлаучылар юк.

– Эх, сезнең бу сикерүләрегез кемгә кирәк? – Абзыйның күзләрендә яшь күренде.

Аның күңелендә ниләр кайнаганы йөзенә чыкты.

– Без бит шул "Шахта" җыры белән үстек, яшәдек, хәтта Донбасста шахтер булып күмер кистек. Сез шуны беләсезме?

Әйе, мин аның үтенечен үти алмадым шул, үти алмадым...

Абзый, үпкәләп, китеп барды.

Шул "Шахта" дигәннән тагын бер нәрсә искә төште.

Еш кына мин Дәү апага кунакка бара идем. Бик олы яшьтә иде ул. Кичләрен озаклап сөйләшеп утырабыз. Ул да "Шахта" җырын бик яратып җырлый. Аның өчен җырның үз тарихы бар. Еламыйча сөйли алмый иде үзе:

– Шул җырны җырлап, авылыбыз белән егетләребезне Донбасска, шахтага озаттык. Безнең абый да шунда китте. Безгә бүләкләр, күлмәклекләр алып кайткалады. Көтеп кенә тора идек. Тик менә берсендә, кайта дип торганда, ул кайталмады. Җырлап киткән җыры гына калды.

Шахталарга син төшәрсең,
Җырлап күмер кисәрсең,
Әмма мине бик сагынсаң,
Бик саргайсаң нишләрсең?..

Сагышлы да, кайгылы да, фаҗигале дә, тарихлы да, үкенечле дә, шул үк вакытта горур да булып яңгырый ул җыр безнең халык тарафыннан!



Таһир ФӘИЗОВ

– Шулай итеп иремнең җанын чакырмакчы булам...




Герман ОГОРОДНИКОВ



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

Игорь КИЙКО




Валентин ДУБИНИН



## ТАБИБЛАР ТОРМЫШЫННАН

*Медицина ул – үз-үзеңне онытып көне-төне хезмәт кую. Хәтта эштән киткәндә дә табиблар, пациентлар, диагнозлар, дәвалау ысуллары һ. б. турында уйлап, күңелләре белән анда калалар. Бу турыда табиблар үзләре менә нәрсә сөйли.*

**Гинеколог:** «Йокысыз төннән соң өйгә кайтып кердем. Хатын миңа: «Безгә җитди рәвештә сөйләшергә кирәк!» Мин аңа гадәттәгечә: «Бар, чишен, ят, әзерләнә тор».

**Невролог:** «Авыруны кабул иткәннән соң чираттагысын чакырыр өчен үз ишегем янына килеп, эчке яктан шакыдым».

**Ашыгыч ярдәм табибы:** «Берзаман салкын тидергән һәм арыган килеш (тәүлек буе аяк өстендә) төнлә кардиограммага болай язганмын: «Иң мөһиме – барыбыз да исән».

**Гомуми практика табибы:** «Авырулар белән аралашып, арып-талып өйгә кайткач, иремнең домофоннан: «Кем бу?» дип соравына: «Табиб», – дип җавап бирдем.

**Анестезиолог:** «Еш кына телефон шалтыраганда: «Реанимация, тыңлыйм сезне!» – дип җавап бирәм.

**Инфекционист:** «Тәүлек буе эшләгәннән соң кесә телефонына: «Дежурный!» – дип җавап бирәсең.

**Отоларинголог:** «Дежурлыкта күп тапкырлар телефоннан җавап биргәннән соң, фонендоскопны авыруның күкрәгенә куеп: «Алло», – дидем.

**Табиб-кардиорадиолог:** «Кич белән кесә телефоны шалтырый, мин: «Радиология», – дип җавап бирәм, ә анда әниемнең тавышы: «Педиатрия тыңлый» (ул педиатр булып эшли)».

**Хирург:** «Бервакыт чиратта торганда бер ир кеше минем кем артыннан торганымны сорады. Мин: «Менә бу авыру артыннан...» – дип җавап бирдем. Ике тәүлек йокламаган идем...»

**Отоларинголог:** «Берзаман маңгай рефлекторын салырга оныткан килеш өйгә кайтып киткәнмен. Тукталышта кешеләрнең миңа сәерсенеп каравының сәбәбен тиз генә аңламадым».

**Ортодонт:** «Ә өч көн рәттән 12 сәгатьлек эштән соң телевизор пульты буенча шалтыратканыгыз булмадымы? Номерны җыеп, пультны колакка куеп, түземсезләнеп җавап көтеп...»

**Мануаль терапевт:** «Ял итәргә вакыттыр... Бүген, таксига утырганда адрес урынына таксистка: «Кушеткага ятыгыз», – дип әйткәнмен.

**Невролог:** «Супермаркетта әйберләр алганнан соң касса чегына имзамны куеп, шәхси печатемне чәпегәнмен! Кассир кызның гаҗәпләнүен күрсәгез!»



# Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Кичә эштән авырыйм дип сорап киттем. Бүген хезмәттәшләремнең өчесе эшкә чыкмаган. Миннән йоктырдык, дип әйткәннәр.

• • •

– Сез тормышны яратасызмы?
– Яратам!
– Ни өчен?
– Ә яратмыйча нишлисең?

• • •

Әбисе оныгына әйтә:
– Өлкәннәрне тыңларга кирәк. Әнә Кызыл Калфак тыңламаган, шуңа күрә аны Соры Бүре ашаган!
– Төгәлрәк булсак, башта ул әбине ашаган!..

• • •

Сыйфатлы реклама һәрчак нәтиҗәле. Менә без кичә каравылчы кирәклеге турында реклама чыгардык, инде бүген үк төнлә безне таладылар.

• • •

Әгәр хезмәт һәм физкультура укытучылары эшләрен ташласа, мәктәп шундук үзен гимназия дип атый башлый.

• • •

Банк таланган. Эксперт-криминалистлар талаучы тарафыннан калдырылган уч эзләре буенча аның озак һәм бәхетле яшәячәген ачыклаганнар, әмма чын мәхәббәткә ирешә алмаячагына төшенгәннәр.

• • •

Хәзер шундый балалар туа башлады ки, "Балалардан саклану көне" булдыру вакыты җиткәндер.

• • •

Беләсеңме, кадерлем, әгәр дә мине чынлап яратсаң, кемгә дә булса башкага кияүгә чыккан булыр идең.

• • •

"Әбиләр эскәмиясе" дигән социаль челтәр ачылган. Сайтының төп төймәләре: "Наркоманлыкка өстәмә" һәм "Фахишәлеккә өстәмә".

• • •

Коньяклар күргәзмәсендә өч йолдызлы коньяк беренче урынны алган, ә шул ук заводның биш йолдызлысы, бары тик өченче урында. Заводның директорыннан сорыйлар:
– Ничек шулай булырга мөмкин?
– Үзем дә аптырыйм, барысын да бер мичкәдән тутырабыз югыйсә...

Игорь КИЙКО



Максим СМАГИН






Виктор ФЁДОРОВ



# НУРИ АРСЛАНОВның ТУУЫНА – 110 ЕЛ



*Ул 1912 елның 19 сентябрендә Казакъстанның хәзерге Петропавловск шәһәрендә дөньяга килә. 1928 елда Казанга килеп, сәнгать техникумының рәсем бүлегендә укый.*

*1933 елның сентябреннән Нури Арсланов Казанда – балалар журналы «Пионер» (хәзерге «Ялкын») һәм «Яшь ленинчы» газетасы редакцияләрендә рәссам вазыйфаларын башкара. Совет-фин, аннан соң Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Нури Арсланов ун елга якын «Совет Татарстаны» (хәзерге «Ватаным Татарстан») редакциясендә – рәссам, 1964-1972 елларда «Казан утлары» журналында шигърият бүлеге мөдире булып эшли.*

*1972 елдан ул бөтенләе белән профессиональ язучы хезмәтенә күчә.*

*Аның шигъри талантлы, осталыгы, әсәрләрендәге фикер тирәнлеге, тематик киңлеге һәм эмоциональ тәэсир итү көче китаптан китапка үсә-чарлана бара.*

*Шул ук вакытта Нури Арсланов Шәрык поэзиясе классикларының, гомумтөрки әдәбияты классикларының шигъри әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә, алар тәэсирендә үзе дә Шәрык классик поэзиясе үлчәмендә һәм формаларында шигырьләр, рөбагыйлар яза.*

*Шагыйрьнең күп кенә лирик шигырьләре композиторлар тарафыннан музыкага салынган. Ул җырларны татар җыр сәнгатенең гүзәл үрнәкләре исәбенә кертергә мөмкин.*

*Нури Арсланов – бай шигъри мирас калдырган шагыйрь. Үзе исән чагында аның утыздан артык китабы басылып чыга, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Шулай ук «Почет Билгесе», Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Халыклар дуслыгы орденнары белән бүләкләнә.*

*Нури Арсланов 1991 елның 12 апрелендә вафат була.*

## НӘСЫЙХӘТ

Наби Дәүли тагын: – Дидактика! – дияр.
Дисә-дияр, бәлки бер файдасы тияр.

Ачулансаң, ачулан, тик явызланма,
Хөрмәт күрсәт, – яраклашма, сагызланма.

Бул булалсаң әре, ләкин эреләнмә.
Сүзең якла, – җаһилләрчә киреләнмә.

Гайрәт белән усаллыкны бутый күрмә.
Горурлансаң горурлан, – мактанып йөрмә.

Түбәнчелек – әйбәт, ләкин түбәләнмә.
Ирешсәң данга, – бер дә әллә кемләнмә.

Канықма көнләшүдән, дустанә көнләш,
Мәйдан тотар булсаң, – аяк чалмый көрәш.

Тыйнак булу әле – йомшак булу түгел,
Һөҗү-калҗыңлы булсаң бул, – чамаңны бел.

Кабат кирәк булыр кое, – төкермә син.
Көчек булсаң була бир, – айга өрмә син.

## "ШАГЫЙРЬЛӘР" ТУРЫНДА

Борынгыда халык якыннары
Язмаганнар кәгазь я тузларга, –
Чөнки укый-яза белмәгәннәр,
Сөйләгәнәр көйләп кубызларда.

Безнең заман "шагыйре" ул башка:
Укый-яза белә, сөйли белми, –
Һәр белемле бәндә шигырь яза,
Кубызы юк, ләкин, көйли белми.

Кирәк кыюы, кирәк базмаганы
Яза бирә "тузга язмаганны"...



## ТЫЛСЫМЛЫ ИРТӘ

Болыт кызы уйный
Кояш арфасында, –
Язгы иртә тыңлый
Яшел арбасында.

Ул атларын җиккән,
Бар да яшел яллы,
Япмалары чиккән,
Һәр бизәге җанлы.

Калгый серле моңнар,
Җир тирән тын ала,
Сызыла алтын кыллар
Чыңлап тора һава.

Яфраклардан тама
Чык-яшь бөртекләре,
Баллы дымын кага
Чәчәк керфекләре...

Миңа язгы назның
Сере аңлашыла:
Мин утырам язның
Яшел арбасында.

Менә чыгам юкка –
Эреп бетәм мин гел –
Мин һавада, чыкта...
Мин – беркем дә түгел.

Аң шат ирек тоеп,
Ни сан матдә тәнгә:
Калгып торам оеп,
Бөтен дөньям – мәгънә!

Болыт кызы кигән
Купшы көмеш киемен;
Бер аңлармын микән
Серен хәят көенең?..

Сылу чакыра көлеп,
Рухым күккә менә –
Гаҗәп моңнар кереп
Тула күкрәгемә!..

## САЛАТ ФАҖИГАСЕ

Куйсаң турап, яргалап:
Яшел кыяр да – салат,
Торма-кишер дә – салат,
Помидоры да – салат...
Кәбестәсе дә – салат...
Чын салатның исе дә юк, –
Салатның эше харап!..

Исеме бар, үзе юк,
Үзе юкның – күзе юк...
Туралган барлык яшелчә
Әверелгәндәй "салат"ка,
Кайберәүләр яраклашып
Яшиләр
яхшы атка...

## НӘНИ ТАКМАКЛАР

***АЧЫДАН АЧЫ***

Ачыдан ачы ни ачы?
Туры әйткән тел ачы.
Шундый туры әйтә торган
Телләр күбрәк булсачы.

***ТӨЧЕДӘН ТӨЧЕ***

Төчедән төче ни төче?
Риторик шигырь төче.
Ялтырап торса ды тышы,
Калтырап тора эче.

***ТҮБӘННӘН ТҮБӘН***

Түбәннән түбән кем түбән?
Ялагай бәндә түбән.
Чинга карап, табан ялап,
Урын эзерли түрдән.






Бакча-дача сезоны, ә урлау-талау – гел искечә. Кулыма каләм алдым да офисның описен эре хәрефләр белән язып, ишек пыяласының эчке ягына беркеттем. Гарык булдым инде бу хәлдән: мин бакчага алып киләм, кемдер бакчадан алып китә. Даими рәвештә!

Ниһаять игъланны язып беркеткәч, әйбер югалу бетте!

Хөрмәтле профессиональ фатир басучылар!

Өйдә бер генә җүнле әйбер дә юк. Ишекне ватып керү – тәрбиясезлек. Аяк киемнәрегезне, мәчеткә кергәндәге кебек, салып керегез. Каты махмырдан кулларыгыз калтыраса, ботинкаларыгызның шнурын чишеп тормагыз, келәм-коверга сөртеп кенә керегез. Шул чүпрәк астында – ачкыч. Киткәндә ачкычны шунда куеп калдырыгыз... Башкалар турында да уйлагыз. Аларның да яшисе, урлыйсы килә бит...

Хәзер описьне игътибар белән укыгыз, хәреф хаталарын төзәтеп тормагыз.

1) Самогонный аппаратны участковый алып чыгып киткән. Бер айдан китерәм, дип язу калдырган. Һаман китерми... Эзләп маташмагыз.

2) Холодильник эшләми. Чыгарып ташларга – жалко. Хәзер ул китапханә хезмәтен үти. Анда Ленин бабайның "Сайланма әсәрләр"е, Марксның "Капитал"ы, Зөлфәт Хәкимнең "Карак", Алмаз Хәмзинның "Озак яшисең килсә" исемле китаплары тузан җыюдан качып ята. Ә "Татар һәм секс" дип аталган китапның фотоларын карагыз да тиз генә урынына куегыз, чөнки аны оныкларым бик тә яратып укый. Китап урынында булмаса, баш бетте. Муеныңа таш бәйләп, Казанкага салабыз, дип куркыталар.

3) Радио юк. Аны чираттагы талау вакытында, тикшереп-нитеп тормыйча урлап киткәннәр.

4) Идән астына яшереп куйган одеколон, лосьон, денатуратларны эзләп интекмәгез. Чираттагы запой вакытында хатын аларның тамчысын да калдырмыйча эчеп бетергән.

5) Утюг искергәч, хатын аны күрше ханымга бүләк итте. Ток сугып, чак исән калды бичара. Утюг бардыр дип, эзләп йөрмәгез.

6) Резин көймә өч җиреннән тишек, дүрт урыннан су керә. Урлап китсәләр, сөенер идем, дип, юри караклар йөри торган сукмакка куйдым. Әллә тишеген күрәләр, әллә ярыгын сизәләр – көймә һаман шул урында ята...


7) Баян шәп иде! Махмырга чыдый алмагач, теге участковыйга барып, ике шешә самогонга алыштырып кайттым. Хәзер баянсыз гына җырлашып утырабыз. Дөресрәге, исереклар көен үйнаудан котылдым.

8) Тычкан тәбәсенә куйган сырны, зинһар, алып ашамагыз. Кызганыгыз. Алар да җан иясе бит. Агуны сырга күп сипмәдем, запойда чакта үзем алып ашыйм.

9) Кашык-савытларны, төсле металл дип, күптән алып чыгып киттеләр. Хәзер ризыкларны мунча чүмеченә салып ашыйбыз, ә эчемлекләрне борынының гына йотабыз. Кем әйтмешли, спартанский образ жизни.

10) Бөтенләй хаерче икән болар, дип әйтмәсеннәр өчен, чүплектән, тузанын сөртеп, черно-белый телевизор алып кайтып куйдык һәм урамга, бөтен кешеләрдән уздырып, иң биек антенна ясаттык. Менә шулай, хөрмәтле фатир басучылар. Профессиональ эшегездә уңышлар телим. Берүк, килсәгез, өйне биклэп, ачкычны келәм астына куеп калдырыгыз!

**Кирам САТИЕВ,**
**Татарстанның халык артисты.**




Ринат АБЗАЛОВ




**САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ**

1923 елдан чыга.

**№ 8 (1921) август 2022**

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, яки https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылу алалар.

**Язылу индекслары:**
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.08.2022 ел.
Тираж – 2676 Заказ О-2196

**Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.**

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-64.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

# Уйна да, уйла да!

ЯЗУЧЫ ГАЗИЗ ...
ХАЛЫК ЖЫРЫ
ВӘКИЛ
КАВКАЗ ХАЛКЫ ВӘКИЛЕ
... МӨЛКӘТ
"... АЙ, ТУЗ БАШЛЫ"
... ТҮГҮ
КАНЦЛЕР ... ШОЛЬЦ
"ҮЗЕМ ЧАПКАН ПЕЧӘННӘРНЕ БЕР ТУЙГАНЧЫ ..."
ШАГЫЙРЬ ЛӘБИБ ...
"ЗӘҢГӘР ..."
ДИН ӘҺЕЛЕ
КӨЧ, КУӘТ
ДӨЯ ДӘ БҮЛӘК, (-1) ... ДӘ БҮЛӘК
КЫЛЛЫ ИНСТРУМЕНТ
"... АВЫЛЫ КӨЕ"
"ЧАЙКАЛА ... КЫРЛАРЫ"
АЮНЫҢ "ФАТИРЫ"
ЧЫРШЫ БОТАГЫ
...-СУ
БИКТАҺИРОВ
НОТА
"АК КҮБӘККӘ БАТКАН ... ЛАР"
САБЫР ТӨБЕ САРЫ ... (-1)
"... ИРКӘМ, ... ИНДЕ"
"АК ЧӘЧӘКЛӘР КЕБЕК ... ЯВА"
ЮЛБАРЫС ...
АВТОРИТЕТ
... (-2) ҮРДӘК
"УЙНЫЙ СУДА АЛТЫН ..."
ГЕКТАР
... РӘНГУЛОВА
"ТАЛЫН ЮШ ... БӘРКИ СИРЕНЬНӘР"
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МАШИНАСЫ
ӘНВӘР ...
... ИЛЬЯСОВ
(-1) АТНЫҢ БАЛАСЫ

Ринат АБЗАЛОВ төзеде

## ТАБЫШМАК БИЛ АЛЫШМАК

**1.** СССРда кәшбек булганмы?

**2.** Син аны рестораннарга йөртәсең, кыйбатлы коктейльләр белән сыйлыйсың, барлык хезмәт хакыңны аңа тотасың. Нәтиҗәдә, ул синнән баш тарта.

**3.** Хатын-кыз сумкасында нәрсә юк?

**4.** Иң юкка-барга ышанучан хайваннар?

**5.** Ни өчен сәүдә үзәкләрендәге каравылчылар бераз боек?

**6.** Кунаклар кемнәр ул?

**7.** Беренче никах төнендәге яшь парларның яраткан шөгыльләре?

### ҖАВАПЛАР

1. Әйе. һәм ул буш шешәләрне җыю һәм тапшыру дип аталган. 2. Бавыр. 3. Урын. 4. Тукран һәм дөя: беренчесе бертуктамый агач шакылдата, икенчесе һәрвакыт төкерергә тырыша. 5. Алар – үзләренең хатыннарын кибет янында көтеп торучы ирләр, ә тегеләре аларны алып китмиләр. 6. Үз өендә трусиктан гына йөрергә комачаулаучылар. 7. Туй фотоларын соцчелтәрләргә чыгару белән маташу.

**Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.**

Чайнвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 7 нче санында басылган чайнвордның тикшерү сүзе – **«КАЙТАМ БАЛДЫЗ ТУЕННАН»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

**Г. БАҺАВЕТДИНОВ** (Чаллы),
**Б. ШӘЙХЕТДИНОВ** (Алексеевский р-ны, Урта Тиганале ав.),
**С. ШӘЙХУЛЛИН** (Казан).

Җиңүчебез – Чаллыдан **Гали БАҺАВЕТДИНОВ!**



# Сәер кешеләр

Василий АЛЕКСАНДРОВ




Вячеслав ШИЛОВ




Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО





